**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«09» 08 2024 ел Яр Чаллы № 3619

«Җир кишәрлекләрен милеккә сату яисә җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзүгә хокуклар сату буенча сатулар уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2016 елның 15 июлендәге 3275 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 7 июлендәге 385-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Җир кишәрлекләрен милеккә сату яисә җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзүгә хокуклар сату буенча сатулар уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2016 елның 15 июлендәге 3275 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 54 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 10 пунктчаны өстәргә:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта ээшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 4 өлешендә каралган дәүләт мөлкәте исемлегенә яисә муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән җир кишәрлегенә карата ташламалар турында, әгәр мондый ташламалар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән булса.»;

1.2. 256 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 4 өлешендә каралган дәүләт мөлкәте исемлегенә яисә муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукционда

катнашу өчен, гариза бирүчеләр үзләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына карауларын күрсәтелгән Федераль закон нигезендә алып барыла торган Бердәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары реестрыннан документ формасында кәгазьдә яки электрон документ формасында мәгълүмат бирү юлы белән белдерәләр яисә күрсәтелгән Федераль законның 4 статьясы 5 өлеше нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына кертү шартларына туры килүләрен белдерәләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хабибуллин